**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“16” ноябрь 2023 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 16 ноябрендә «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кызыл Утар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, тавыш бирү хокукына ия булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе оборона министрлыгы белән контракт төзегән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Кызыл Утар авылы территориясен чистарту (агачлар кисү, үлән чабу);
2) урам утларына хезмәт күрсәтү өчен түләү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 67 (алтмыш җиде) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 39 (утыз тугыз) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 39 (утыз тугыз) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. “Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кызыл Утар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, тавыш бирү хокукына ия булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе оборона министрлыгы белән контракт төзегән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле

әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Кызыл Утар авылы территориясен чистарту (агачлар кисү, үлән чабу);
2) урам утларына хезмәт күрсәтү өчен түләү.

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кышлау авыл җирлеге башлыгы Кашшапов А.Х.